КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 11 июль г.Казань № 665

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү

буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 18 август, 705 нче; 2021 ел, 11 февраль, 70 нче; 2021 ел, 24 май, 366 нчы; 2021 ел, 30 октябрь, 1026 нчы; 2022 ел, 22 гыйнвар, 39 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 пунктка түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) хосусый медицина оешмасы экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмаска тиеш.»;

8 пунктның «в» пунктчасында «максатларын,» сүзен төшереп калдырырга;

9 пунктның «а» пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«хосусый медицина оешмасының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат булган оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган документ;»;

22 пунктта:

унҗиденче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«грант алучының, грант алучы белән төзелгән шартнамәләр нигезендә акча алучы затларның (дәүләт (муниципаль) унитар предприятиеләреннән, устав (җыелма) капиталларында гавами-хокукый берәмлекләр катнашында хуҗалык ширкәтләреннән һәм җәмгыятьләреннән, устав (җыелма) капиталларында әлеге ширкәтләрнең һәм җәмгыятьләрнең катнашуында коммерция оешмаларыннан тыш) аларга карата вәкаләтле орган тарафыннан грант бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә, шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә, шулай ук дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә грант алучының грант бирү тәртибен һәм шартларын үтәвен тикшерүгә ризалыгы;»;

егерме алтынчы абзацта «, максатларын» сүзен төшереп калдырырга;

31 пунктның өченче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

34 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«34. Вәкаләтле орган грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен (шул исәптән грант бирү нәтиҗәсенә ирешү өлешендә) үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Грант алучының грант бирү шартларын һәм тәртибен үтәвен тикшерү Россия Федерациясе Бюджет кодексының 2681 һәм 2692 статьялары нигезендә дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Грант бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән грант бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешүдән һәм грант бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле

чараны төгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.».

2. Бу карар (бу карарның 2023 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктындагы ундүртенче абзацыннан тыш) рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 – 2024 елларда Татарстан Республикасында хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирендә яшәүче, Россия Федерациясе гражданнары булган затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашыру турында» 2020 ел, 3 февраль, 72 нче карары белән расланган 2020 – 2024 елларда хосусый медицина оешмаларына – хосусый медицина оешмаларын Россия Федерациясе гражданнары булган, шул исәптән авыл җирлегендә яшәүче, 65 яшьлек һәм өлкәнрәк затларга медицина-социаль хезмәтләр күрсәтүгә җәлеп итү буенча пилот проектын гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгымнарны финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр рәвешендә грант бирү кагыйдәләренең 7 пунктындагы «б» пунктчасының, 9 пунктындагы «г» пунктчасының гамәлдә булуын 2023 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин